**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь, 2025** **№ 2**

**«Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Оштарма авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 24 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Оштарма авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын түбәндәге адреста урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә: Аман-Оштарма авылы, Ленин урамы, 22 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Оштарма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Березняк авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы: Р.Ф. Шәрипов